Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

КАРАРЫ

КАРАРЫ

01.07.2022 ел. Менделеевск ш. №124

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 43 статьясы нигезендә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. «Менделеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнары структурасын раслау турында» 2015 елның 27 октябрендәге 18 номерлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты Аппараты структурасына 2022 елның 1 июленнән түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте, шәһәр хуҗалыгы һәм сәүдә бүлеге башлыгы урынбасарының 1 штат берәмлеген алырга һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының сатып алулар бүлегенә җитәкче урынбасарының 1 штат берәмлеген кертергә;

1.2 Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлегенә баш белгечнең (тәрҗемәче) 1 штат берәмлеген кертергә;

1.3 «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының сатып алулар бүлеге» исемен «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының сатып алулар һәм сәүдә бүлеге» дип үзгәртергә;

1.4 «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге, шәһәр хуҗалыгы һәм сәүдә бүлеге» исемен «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының торак сәясәте һәм шәһәр хуҗалыгы бүлеге» дип үзгәртергә.

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: www.mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының финанс-бюджет мәсьәләләре буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары Л.К.Галиева

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының _______ _______елның ________ ________ карарына кушымта

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының
Аппарат структурасына 2022 елның 1 июленнән үзгәрешләр

| № т/б | Вазифаның аталышы | берәмлекләр саны |
|---|---|---|
| | **Сатып алулар һәм сәүдә бүлеге** | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Башлык урынбасары | 1 |
| | **Архив бүлеге** | |
| 1 | бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | баш белгеч | 1 |
| | **Торак сәясәте һәм шәһәр хуҗалыгы бүлеге** | |
| 1 | бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | баш белгеч | 0,5 |